# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

(V чакырылыш)

V чакырылышның I утырышы

**КАРАРЫ**

«24» сентябрь 2025 ел № 3 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгын сайлау турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 елгы 33-ФЗ санлы Федераль законның 19 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты, 5 өлеше, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 22.11.2024 елның "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында"гы № 28 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставының 39 статьясы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының V (5) чакырылыш беренче утырышы хисап комиссиясенең 24.09.2025 № 3 беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгын сайлау турында яшерен тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга.
2. V (5) чакырылыш Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутаты Шәфигуллин Аяз Әдип улын Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башлыгы итеп сайларга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.
4. Әлеге карар аңа имза салынган көннән үз көченә керә.

V (5) чакырылыш
Татарстан Республикасы Ютазы район
Советы депутаты, рәислек итүче С.Ә. Галиев